وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклапябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

6+

№15 (158). 12 октябрь 2012 / 26-зөлкагдә-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



25 октябрь – Корбан бәйрәме

▷2◁



Үз көнен үзе күрә торган мәктәп

▷2-3◁




Дәүләтнең дини сәясәтендә – либеральләштерү

▷3-4◁

# Хаҗ кылуның хикмәте

**Хаҗ - ислам дине нигезләренең берсе булган олуг бер гыйбадәт. Хаҗ дип Мәккәи-Мөкәррәмәгә барып, шәригатьтә күрсәтелгән рәвештә билгеле бер гамәлләрне кылу белән бергә Кәгъбәтулланы зиярат кылуга әйтелә. Хаҗ - бөтен гыйбадәтләрне, ягъни җан, тән һәм мал гыйбадәтләрен үз эченә алу өстенә мөселманнар өчен бер гыйбрәтле вакыйга да булып тора.**



Ислам диненең башка баганаларыннан аермалы буларак, ул билгеле бер вакыт эчендә һәм Җир шарының билгеле бер урынында кылына. Ә намаз, ураза, зәкят гыйбадәтен, җаена карап, теләгән урында кылырга була.

Аллаһы Тәгалә коллары өчен кагыйдә һәм кануннарны шундый итеп билгеләгән, аларны үтәгәннең файдасын мөселманнар бу һәм теге дөньяда да күрәчәк. Коръәни-Кәримдә хаҗ кылудан булган файда һәм зирәклек турында әйтелә.

***Хаҗ кылуның кайбер хикмәтләре:***

**1. Мөселманнарны берләштерү.** Ислам дине дөнья халыклары арасында дустанә мөнәсәбәтләр урнашуга зур әһәмият бирә. Ислам кануннары мөселманнарның берләшүенә ярдәм итә. Мәсәлән, бер квартал мөселманнары якындагы мәчеттә фарыз җәмәгать намазларын кылу өчен көнгә 5 тапкыр очрашалар. Мөселманнар атнага бер тапкыр гына булса да җомга намазына мәчеткә килергә тиеш. Ә Җир йөзендә яшәүче мөселманнарның хаҗ вакытында бер-берсе белән очрашырга мөмкинлекләре бар.

**2. Мөселманнар бердәмлеген яңартып җибәрү.** Барлык милләт мөселманнары бер үк йола һәм кагыйдәләрне үтиләр, барлык кешеләр өчен Бер булган Аллаһы Тәгаләгә үтенечләрен юллыйлар, Кәгъбәтулла ягына юнәлеш тоталар.

**3. Җирнең төрле почмакларында яшәүче мөселманнарны Ислам дөньясының үзәге - Бер Аллаһы Тәгаләгә ышану дине таралган Мәккә шәһәренә тарту.**

**4. Мөселманнарның тигезлеген белдерү.** Хаҗ кылу вакытында беркемнең дә бернинди өстенлекләре юк: хуҗа белән хезмәтче, министр белән эшче - барысы да бер дәрәҗәдә булалар. Бу - Аллаһы Тәгалә каршында бөтен кеше бертигез икәнлеген исебезгә төшерә торган урын. Шулай ук хаҗ барыбызның да курку хәлендә киемсез, исәп-хисап алдында торачагыбызны; байлыгыбыз да, затлы нәселдән булуыбыз да, җәмгыятьтә тоткан урыныбыз да булыша алмаган Кыямәт көне турында исебезгә төшерә.

**5. Хаҗ - мөселманнарның иманын ныгыту өчен пәйгамбәрләр һәм сәхабәләр турында искә төшерү ул.** Хаҗ йолалары үткән һәрбер урын нинди дә булса тарихи вакыйга белән бәйле. Дөньядагы беренче кеше атабыз Адәмне (гс) һәм бөтен дөньяны су баскач ишелгән Кәгъбәтулланы яңадан төзүче Ибраһимны (гс) һәм Исмәгыйльне (гс) искә төшерәбез.

Шулай ук мөселманнар Кәгъбәне төзекләндерергә булышучы, аны әйләнеп үтүче, "Әл-Хаҗәр әл-әсвад" ташын үбүче рәсүлебез Мөхәммәтне (сгв) күз алдына китерәләр. Сафа һәм Мәрва калкулыклары хаҗ кылучыларга, улы Исмәгыйль пәйгамбәргә су эзләгән Хаҗәр (аңа Аллаһның рәхмәте булсын!) турында искә төшерәләр. Минада ташлар ыргыту вакыты, бу җирдә ташлар ыргытып, үзеннән Иблисне куган Ибраһим пәйгамбәр һәм шул урыннан әтисе корбан итү өчен алып киткән Исмәгыйль пәйгамбәрне искә төшерә.

Гарәфә тавында исә хаҗилар саубуллашу хаҗын кылучы Аллаһы Тәгалә илчесен күз алдына китерәләр. Ул аларга васыять итеп, болай дигән: "И кешеләр, Аллаһы Тәгалә бер генә, һәм сез барыгыз да Адәм токымыннан, Адәм җирдән ясалган, гарәпнең гарәп булмаган кеше алдында өстенлеге - тәкъвалыгында гына була ала. Бер-берсе белән көрәшкән кяферләргә охшамагыз..."

**6. Хаҗ гамәле - хаҗины тәрбияләү дә ул.** Сәфәрдә төрле кыенлыклар белән очрашканда ул сабырлык күрсәтергә тиеш. Хаҗда бер урында бик күп мөселман очраша, һәм монда кыенлыклар белән очрашканда чыдамлылык, тыйнаклык, әдәплелек, күндәмлек күрсәтергә кирәк. Хаҗ шулай ук кешедә юмартлылык тәрбияли: Корбан бәйрәме көнендә корбан чалып, мохтаҗларга сәдака тараталар.

*Үзәкләшкән дини оешма –*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

# ТРАДИЦИОН ИСЛАМ

## Терактлар эшләүче кешеләр дә үзләрен мөэмин-мөселман дип атыйлар.

**Соңгы вакытларда социаль челтәрләр "Ислам сүзенә "традицион", яки "традицион булмаган" дигән сүзләр тагу кемнең башына килде?!", "Гомумән, нинди традицияләр булырга мөмкин инде ул диндә?!" - дигән сораулар һәм шуларга төрле аңлатмалар бирү белән чуарланып бетте.**

Матбугат битләреннән, телевизор экраннарыннан, интернет порталларыннан ислам темасы төшми. Мондый популярлыкка традицион исламга еш кына ялгыш аңлатма бирү дә ярдәм итә. Ә андый төгәллектән бик ерак торган аңлатмалар традицион исламны тулысынча аңлап бетермәү аркасында килеп чыга.

- Кайберәүләр "традицион ислам" төшенчәсен ялгыш аңлыйлар, кайберәүләрдә ул шик уята, - ди мөфти вазифаларын башкаручы Габдулла хәзрәт Әдһәмов. - Башкасын куркуга сала, күпләр аның тарафдары булыр өчен, мәчеттә сәдака калдыру һәм намаз уку җитә дип уйлый.

Аның фикеренчә, Ислам бервакытта да традицияләргә каршы булмаган, тик аның таралышын билгеле бер кысаларда чикләгән генә. Гарәпләрдә, мәсәлән, җаһилият заманнарында ук ир кеше никах укыткан вакытта, бары тик ярәшелгән кызның әтисенә генә мәһәр түли торган булган. Ислам кабул ителү белән, мәһәр бирү юкка чыкмаган, ә аңа бары бераз үзгәреш кенә кертелгән, хәзер инде ул кияүнең булачак хатынына биргән бүләге булып санала башлаган.

Рөстәм Батыр "традицион ислам" төшенчәсе башка отышлырагы булмау сәбәпле генә кабул ителгән термин дип исәпли. Хәтта традицион исламның төп идеологларының берсе булып исәпләнгән Вәлиулла хәзрәт Якупов та, аның сүзләренә караганда, төрле терминнар кулланган: традицион ислам, мәзһәби ислам, Пәйгамбәребез (сгв) исламы. "Ислам бар мөэмин-мөселман өчен бер булса да, кайбер мөселманнарның соңгы еллардагы карашлары бездә элеккеге вакытларда ук булган карашлардан аерыла башлады. Һәм дә бездә гасырлар буе булган карашларны ачыклап әйтергә ихтыяҗ туды", - ди иде ул.

Рөстәм хәзрәт диннең төп асылын аңламый торып традицион исламның ни икәнлеген төгәлрәк белү мөмкин түгеллеген әйтеп, сөйләшүне ерактан башлады: "Ислам ул - шәхеснең трансформация юлы, үзеңнең мин-минлегеңне, эгоцентризмыңны җиңеп чыгу, "сөекле" үзең өчен генә түгел, ә Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен игелекләр кылу".

Шәхеснең шул дәрәҗәдә рухи үсеп җитлегүе традицион исламны формалаштыручы өч фән: 1) ислам тәгълиматы; 2) ислам хокукы; 3) мөселман этикасы кысаларында башкарыла. Вакытлар үткән саен бу дисциплиналар тәҗрибәсе үсә бара, ул билгеле бер мәзһәпләрдә туплана. Вакыт сынавын үткән бу мәзһәпләр - шул традициянең үзе була да инде. Матуриди мәктәбе, хәнәфи мәзһәбе әһелләре - традицион ислам тарафдарлары.

Табигый, үзеннән-үзе шундый гади бер сорау туа, безнең бабаларыбыз сайлап алган бу мәзһәпләр башкаларыннан принципиаль рәвештә ни белән аерыла соң? "Әбу Хәнифә, үзенең тәгълиматын төзегән вакытта, безнең бар фикер каршылыкларыбызны да Аллаһы Тәгалә хөкеменә калдырырга кирәк, дип әйтә торган булган", - дип җавап бирә Р.Батыр. - Андый фикер йөртү, Аллаһка ышану бары тик ике өлештән тора дигән вакытта, алай

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ХАҖИЛАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ӨЧ ТӨРКЕМЕ ИЗГЕ СӘФӘРГӘ ЧЫКТЫ

**11 октябрь көнне иртәнге сәгать биштә (5.00) Казан халыкара аэропортыннан "ДУМ РТ Хадж" программасы буенча изге хаҗ сәфәрен кылырга җыюнучы мөселманнарның беренче өч төркеме Мәдинә шәһәренә юл тотты.** Хаҗилар аэропортка төнге икедә (2.00) җыелдылар, теркәлү өчен кирәк булган документлар тикшерелде, оештыру моментлары каралды. Аларны озатырга имам-мөхтәсибләр, хаҗ сәфәрен алдагы елларда кылган тәҗрибәле хаҗилар, мөселман уку йортлары мөгаллимнәре җыелган иде. Хаҗилар арасында әле беренче тапкыр гына изге сәфәргә җыюнучылар да, шул ук вакытта 7-8 тапкыр баручылар да бар иде.

Хаҗиларны озатырга Татарстан мөфтие вазифаларын вакытлыча башкаручы Габдулла хәзрәт Әдһәмов һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Аппарат җитәкчесе Ришат Хәмидуллин да килгән иделәр.

### "НЫК ИМАНЛЫ" КУБОГЫНА ФУТБОЛ ЯРЫШЛАРЫ УЗДЫРЫЛАЧАК

**2012 елның 14 октябрендә Казан мәчетләре арасында футбол ярышлары үткәрелә.** Мәчет командалары "Нык иманлы (Сильноверующий)" кубогы өчен көрәшәчәк. Чараны, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм "Зәкят" фонды ярдәме белән, "Алтын урта" татар мөселман яшьләре җәмгыяте оештыра. Матч Үзәк стадион янындагы Футбол һәм җиңел атлетика манежында унынчы яртыда (9.30) башланачак.

Ярышларда Әниләр, Кабан арты, Ризван, Апанай, Мәрҗани мәчете командалары катнашачак.

### III САМАТОВ УКУЛАРЫ ҮТКӘРЕЛӘ

**Бүген Мәрҗани мәчетендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте III Саматов укуларын уздыра. Әлеге чара 2010 елдан башлап Габделхак хәзрәт Саматов туган көндә үткәрелә.**

Габделхак хәзрәт Саматов (1930-2009) - XX йөз ахыры - XXI йөз башы күренекле дин әһелләренең берсе, күп сандагы дини китаплар авторы, нәзарәтнең беренче казые. Ул - татар халкының инкыйлабка кадәрге чордагы бай дини мирасын тудыручы дин әһелләренең дәвамчысы.

Саматов укулары Габдехак хәзрәтнең мирасын барлау, эшчәнлеген өйрәнү һәм традицион ислам кыйммәтләрен ачу максатыннан оештырыла. Чара кысаларында күркәм динимилли эшчәнлек алып баруы белән аерылып торган шәхесләргә Г.Саматов исемендәге "Рухи мирас" премиясе тапшырыла. Әлеге чара үткәрелгәннән соң конференциядә ясалган чыгышлардан торган җыентык нәшер ителә.

Быел узачак Саматов укуларына Ханты-Манси автономия округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматов, Чуашстан мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов, Самара өлкәсе мөфтие Талиб хәзрәт Яруллин һ. б. дин әһелләре, шулай ук дини оешмалар җитәкчеләре, Габделхак хәзрәтнең укучылары, чордашлары чакырылган.

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

2012 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ

# Коръән уку әдәбе



*(Ахыры. Башы газетабызның 5 октябрь санында.)*

19. Әгәр дә Коръәнне укучы үз тавышын үзе ишетмәсә, мондый укуны тулы сыйфатлы дип әйтеп булмый. Ләкин Коръәнне эчтән укырга да була, бу бары тик укучының үз ниятеннән генә тора. Әгәр дә риялыкта (ясалма, мактанып укуда) шик бар яки кычкырып уку башкаларга комачаулый икән, эчтән уку тиеш. Әгәр дә сез башкаларга комачауламыйсыз, сезне риялык шиге астына алырга урын юк икән, сезнең укуыгыз сезне һәм башкаларны рухландыра икән, кычкырып уку яхшырак.

20. Аятьләрнең чын мәгънәсенә төшенмичә, аның рус яки башка бер телдәге тәрҗемәсенә генә таянып, ул аятьләрнең чын мәгънәсен өстән-өстән генә, үз белдегенчә аңлатырга тырышу - Коръәнне санга сукмау билгесе. Коръәннең мәгънәсен төгәл аңлата алмау кешеләрне ялгыш юлдан җибәрә, һәм дә андый кеше, башкаларны Коръән буенча яшәргә чакырган олуг сүзләр артына яшеренеп, чынлыкта (хәзерге вакытта моны ваһһабчылар һәм башкалар эшләгән кебек) Исламга каршы чыгыш ясый. Андыйлар турында Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): "Кем Коръәнне үз белдеге белән аңлата - үзләренә җәһәннәм утында урын әзерләсеннәр", - дигән. (Әт-Тирмизи, Әбу Давыд һәм ән-Нәсаи).

21. Коръәнне чистартылмаган авыз белән уку хупланмаганга, аны чайкап алу һәм сивак куллану сөннәт санала.

Әгәр дә Коръәнне укыган вакытта пауза ясалса, яңадан укый башлаганчы теш һәм уртларны сивак белән чистартып алу һәм "Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражиим" дип әйтү тиеш.

22. Әгәр дә укыган вакытта кикерәсе килә (кикертсә) яки йокы килүдән иснәтә башласа, укуны туктатырга кирәк. Мондый халәттән соң тынычлангач кына укуны дәвам итәргә була.

23. Коръәнне йокымсырау, йокы басу халәтендә уку хупланмый, чөнки бу вакытта ялгышу ихтималы зур.

24. Коръән укуны дикъкать белән тыңлау сөннәт санала.

25. Вакыт-вакыт Коръәнне өйдә дә укырга кирәк. Хәдистә: "Үз йортларыгызны Коръән укылмый торган кабергә әйләндермәгез", - диелә (Бәйхакый).

26. Коръәнне укучы, игътибарын шулкадәр дәрәҗәдә тупларга тиеш, гүяки ул Аллаһның каршында басып тора.

27. Коръәнне базарда, тавышкөлке, кычкырып сөйләшүләр күп булган шау-шулы, кешеләр ашапэчеп я күңел ачып утырган урыннарда уку ярамас.

28. Коръән укучыга уку вакытында башка сүзләр әйтергә; көләргә; бармаклар белән уйнап утырырга ярамый.

29. Сүрәләрне Коръәндә кителгән эзлеклелектә уку сөннәт санала.

30. Коръәнне төркем булып, бер түгәрәккә җыелып уку яхшы: берәү укый, калганнары - тыңлый. Чиратлашып уку да мөмкин.

31. Коръәнне матур тавыш белән укырга тырышырга кирәк. Хәдистә: "Коръәнне матур тавышларыгыз белән бизәгез", - диелгән (Әбу Давыд, ән-Нәсаи, бине Мажа, Хәким).

32. Әгәр дә җыелганнар арасында Коръәнне яхшы укучы бар икән, аннан Коръән укуын үтенеп, аны тыңлап тору сөннәт санала.

33. Коръәнне укып чыккач: "СәдакАллаһы-газыйм вә бәллага рәсүлүһүл-кәрим. Аллахүммәнфәгънә биһи һә бәрик ләнә фиһи вәл-хәмдү лилләһи раббил галәминә вә әстәгъфируллахәл-хәййәлкаййүмә (Бөек Аллаһ хак сүзне әйтте һәм хөрмәтле Пәйгамбәр аны халыкка җиткерде. Әй Аллаһ, Коръәнне уку рәхәтен һәм файдасын бир безгә. Бар мактаулар да Аллаһка - дөньялар Хакименә һәм гөнаһларымны кичерүеңне сорап Сиңа мөрәҗәгать итәм, мәңге Тере һәм Мәңге калучы!)", дип әйтергә кирәк.

34. Коръәнне укып чыккач дога уку - Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сөннәте булып санала. Ул доганы Аллаһ кабул итә һәм аңа җавап бирә. Коръәнне укып чыккач бар гаилә әгъзаларын, кардәшләреңне, якыннарыңны җыю да шундый ук әһәмиятле сөннәт санала. Аллаһтан үзең өчен генә түгел, ә ата-анаң, өйдәгеләрнең барысы өчен дә, бар туганнарың, якыннарың, дус-ишләрең өчен, бар мөэмин-мөселман өчен дә дога кылу, аларның Исламны күтәрүләрен, мөселман хакимнәрен Хак юлдан җибәрүен сорарга кирәк.

Аллаһ безне ярдәменнән ташламаса иде һәм безнең Коръән укуларыбызны кабул итсә иде.

# ҮЗ КӨНЕН ТОРГАН

**Белгәнебезчә, Мөхәммәд (сгв) Коръәни-Кәримнең беренче аятьләре "икъра", ягъни "укы" дип иңә. Пәйгамбәребез (сгв) исә бер хәдисендә: "Һәр мөселман ир-ат һәм хатын-кызга гыйлем алу - фарыз", - диелә. Ул шулай ук: "Гыйлем алган кеше белән гыйлемсез гыйбадәт кылган кешенең аермасы тулы ай һәм аның янында күренгән йолдызлар кебек", - дип белдерә.**

Әлеге хәдисләргә таянып, ислам диненең гыйлемгә нигезләнгәнен күрәбез һәм мөселман кешесе иң әүвәл белемле булырга тиеш дип әйтә алабыз. Ә бездә мөселманнарга белем алырга шартлар тудырылганмы соң? Бу сорауны ишеткәч күпләр, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе, Россия ислам университеты кебек уку йортларын күздә тотып, бер тавыштан: "Әйе", - дияр. Баксаң, бездә мөселман балалары өчен гомуми белем бирү мәктәбе дә бар бит. "Госмания" исемен йөртә торган әлеге шәхси гыйлем йорты, хөкүмәт лицензиясе буенча эшләсә дә, дәүләт тарафыннан финансланмый, ул иганәчеләр, балаларына ислам дине кушканча аң-белем бирергә омтылган мөселман әти-әниләре ярдәме белән үз көнен үзе күрә.

"Госмания" мәктәбе Казан шәһәренең бер читендә, Северный бистәсендәге "Нурислам" мәчете белән янәшә урнашкан. Билгеле, без күреп өйрәнгәнчә, ике катлы, дистәләгән бүлмәле, иркен, киң гыйлем йорты түгел ул. Ә җыйнак кына итеп төзелгән, шулай ук ике катлы итеп эшләнгән бинада урнашкан. Корылманың түбәсендә ярымай балкый. Заманында бу бинаны Вафа хәзрәт Гыйләҗи улы дин сабагы укыту өчен мәдрәсә ачу нияте белән салган. Ул бина "Нурислам" мәчетенеке. "Госмания" мәктәбен ачу эшен беренчеләрдән булып Камил хәзрәт Вәлиуллин башлап җибәрә. 1995 елда Казанда беренче һәм бердәнбер мөселман мәктәбе ачыла. 1995-1996 нче уку елларында беренче сыйныфка 12 бала укырга килсә, хәзер бирелдә 120 укучы белем ала.

Мин "Госмания"гә килгәндә берничә хатын-кыз шау килеп аш-су бүлмәсендә кайнаша иде. Баксаң, рамазан ае уңаеннан балалар һәм әтиәниләр өчен ифтар уздыралар, иртәннән үк шуңа әзерләнәләр икән. "Ышанмассыз, Аллаһы Тәгалә безне менә шулай ярдәменнән ташламый. Уку елы вакытында да балаларга ризык әзерләргә кайчак ит бетсә, Раббыбыз көтмәгән яктан бирә: я берәрсе нәзер әйткән була да, сарык суеп китерә яки корбаннан өлеш чыгаручы табыла", - дип сөйләп китте шундагы мөлаем бер ханым. Кем булуымны әйткәч, мәктәпнең директоры Илсур хәзрәт Фатыйхов килеп җиткәнче, ул мине уку йорты белән таныштыра торырга да ризалашты. Яшерен-батырын түгел, мәктәпне шәһәрдәге заманча уку йортлары белән чагыштырып булмый. Бүлмәләр артык зур, купшы түгел, һәркайсында компьютер кебек җиһазлар да юк. Һәрнәрсә гади, тыйнак булса да, биредә үзенә бер төрле җылылык бөркелә. "Монысы китапханә, - дип таныштыруны дәвам итте ханым. - Укучылар монда яратып керә. Ә менә бу бүлмәгә күптән түгел интерактив такта алып куйдык. Ул безнең мәктәптә бердәнбер. Монда исә кызлар намаз укый, ир балалар, намаз вакытлары җиткәч, мәчеткә керә. Аскы катта тәһарәт алу өчен махсус урын бар. Бездә кызлар мөселманча киенә. Ризык - хәләл. Башка мәктәпләрдәге кебек чыршы куеп, Яңа елны каршыламыйбыз. Безнең өчен иң күркәм көн - гает бәйрәме. Аны зурлап уздырабыз..." Шулай мәктәп эшчәнлеге белән танышып йөргәндә Илсур хәзрәт тә күренде.

- Мин әлеге вазифага моннан өч ел элек алындым, - дип әңгәмәгә кушылды ул. - Директор булып килгәч, мәктәпнең бинасын киңәйтеп, "пристрой" эшләдек, җылылык системасын, электр чыбыкларын алыштырдык.

# 25 ОКТЯБРЬ – КОРБАН БӘЙРӘМЕ

**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Кама буе төбәге казые Рөстәм хәзрәт ШӘЙХИВӘЛИЕВның корбанга бәйле кайбер аңлатмалары:**



- Мөхтәрәм дин кардәшләребез! Шәригатебез буенча корбан бәйрәмендә гает намазы уку һәм корбан чалу каралган. Корбан гает намазы укылганнан соң беренче, яки икенче, яки өченче көнне чалына. Зөлхиҗҗә аеның уникенче көненә кадәр (ахшам намазына чаклы) корбан чалуны төгәлләргә кирәк. Әгәр инде шул вакыттан соң чалынса, корбаны дөрес булмый.

Корбанга безнең якта өч төрле хайван чалына - сарык, кәҗә, сыер; шәригать буенча - дүрт төрле. Бездә аларның дүртенчесе - дөя үрчетелми. Сарыкны кайбер якларда "куй" да диләр. Сарык һәм кәҗәнең бер яше тулган булырга тиеш. Куй булса, ул инде эре сарык. Шушы куйларның гына рөхсәт ителә алты айлыкларын корбанга чалырга. Ә болай сарык, кәҗә - бер, сыер ике яшен тутырырга тиеш. Сарык, кәҗә бер кеше, ә сыер күп дигәндә җиде кеше өчен чалына.

Сыерны чалганда бер кеше ике өлешкә кергән вакытта биш кешегә берәр өлеш кала. Әмма бу очракта кешеләр саны алтыдан артмый. Һәм инде аларның ниятләре фәкать корбан чалуда гына булырга тиеш. Ягъни арадан берсе ит өчен генә дип керсә, калганнар бу хакта белсәләр, аларның корбаннары корбанлыктан үтми. Әгәр бу кеше моны әйтмичә эшли икән, үзе генә гөнаһлы була, башкаларның корбанлыгы корбанлыктан үтә. Шуңа күрә белә торып кемнедер ит өлешенә кертүдән сак булырга кирәк.

Безнең халыкта корбанга бәйле кайбер аңлашылмаучанлыклар яши. Мәсәлән, быел гаилә белән корбан чалабыз, диләр. Икенчеләр: "Быел үземә, алдагы елны хатыныма, аннары балаларыма чалам", - дип әйтә. Корбан гаиләдән түгел, ә мөмкинлеге булган кешедән чалына. Фитыр сәдакасы гаиләнең һәр әгъзасы өчен бирелгән кебек. Гаилә әгъзаларының кайсысының булса да корбан гаете көненә мөмкинлеге булса, ягъни нисабы җитсә, ул һәр елны корбан чалырга тиеш. Бу алар өчен вәҗип гамәл. Көмеш нисабы белән исәпләгәндә, малларының нисабы (бүгенге көндә 20 мең сумга туры килә) тулган вакытта, аларның һәркайсы корбан чала. Шулай да булырга мөмкин: ир-атның нисабы җитми, ә хатынның җитә. Бу очракта корбан чалу хатынга гына тиеш була.

Корбан чалучы хәлле кеше булса, корбанлыгының өчтән бер өлешен мохтаҗларга, икенче өлешен туганнарына, күршеләренә тарата, ә өченче өлешен үз гаиләсе өчен тота. Үзенә калдырмыйча тулаем мохтаҗларга таратса да, дөрес була.

Нисабы җитмәүчеләр арасында да корбан чалырга теләүчеләр очрый. Мондый мохтаҗ кешеләр корбаннары итен таратмыйча үз гаиләләрендә генә тотсалар да ярый, ә корбан чалган өчен аларга әҗер-савап була.

Чалган корбанлыкның тиресен сатып акчасын үзеңә куллану ярамый. Тирене берәр мохтаҗ кешегә сәдака итеп бирү яисә аны сатып шуның акчасын сәдака итеп тапшыру тиешле, әмма сатмыйча күн яисә тун итү дөрес.

Корбанлыкка нинди хайван бара дигәндә, сау-сәламәтләре. Бик арык хайваннар, йөри алмаслык дәрәҗәдә аксаклар, яисә бер колагының, мөгезенең, койрыгының өчтән бер өлеше "һәлак булган" хайваннар корбанлыкка ярамый. (Мөгезне кисү дигәннән, аны бәләкәйдән үк дару белән яндырып үстертмәүчеләр бар һәм шулай ук үзе мөгезсез хайваннар да була. Мондый очракларда корбанга ярый. Ә инде үскән мөгез кисеп алынса яки сугып сындырылса, ярамый). Шулай ук бер күзе сукыр, яки колаксыз, яки койрыксыз (әгәр тугында ук шундый булмасалар) хайваннар корбанга чалынмый.

Корбанны кеше үзе чалса күркәм була. Әмма чала алмаса ышанычлы кешедән чалдыра. Корбан малы чалынганда аның янында тору яхшы. Әмма тора алмаса да дөрес, бу эш мәҗбүри түгел. Шулай ук кайбер кешеләр, догасын белмим дигән сылтау белән корбан чаладан тыелып торалар. Аллаһы Тәгаләгә ният кылып: "Я Раббым Аллаһ, фәлән-фәлән улыннан, фәлән-фәлән кызыннан Үз ризалыгың белән кабул ит, дип әйтәсең дә, "Бисмилләһи Аллаһу әкбәр" дип чаласың. Бернинди дә катлаулылыгы юк. Намазын укый, догасын кыла белмим дип корбан чалмау да дөрес түгел. Корбан чалганнан соң намаз уку да мөстәхәб гамәл, мәҗбүри түгел.

Кайбер урыннарда корбанны пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (сгв) атап чалу гадәте бар. Әлбәттә, ул Аллаһы Рәсүленә хөрмәт күрсәтү булып тора. Әмма шәригатьтә андый әйбер юк. Һәр кеше үзенә чалырга тиеш. Чөнки ул аның үзе өчен вәҗип гамәл. Асып тунарга, сөяген вакларга, этләргә бирергә ярамый дип әйтүләр дә шул урындагы гадәткә кайтып кала. Бу гамәлләр яхшы ният белән кергәннәрдер. Әмма алар шәригатьне бозу булып тора. Әйтик, сөяген вакламыйча сыер малын ничек бүләсең? Корбан малы калдыкларын исраф итеп ташлаганчы эткә бирү дә хәерлерәк түгелме?

# ҮЗЕ КҮРӘ МӘКТӘП



Күреп торганыгызча, бөтен җиргә видеокамера куйдык. Гадәттән тыш хәл килеп чыкканда хәбәр бирү җайланмасы урнаштырдык. Бу эшләр барысы бергә якынча ике миллион сумга төште.

Белем бирү мәсьәләсенә килгәндә, "Госмания"дә дә, башка гомуми белем бирү мәктәпләрендәге кебек үк, дөньяви фәннәр укытыла. Дин, әхлак-әдәп, тәрбия дәресләре әти-әниләрнең теләкләре белән факультатив дәрес, түгәрәк формасында оештырылган. Аларда вакытның күп өлеше Коръәни-Кәримне укытуга бирелә. Беренче сыйныфтан ук егет-кызлар өстәмә дәрестә "Һәфтияк шәриф"тәге кыска сүрәләрне өйрәнә. Коръәни-Кәримне камилрәк белергә, аны ятларга теләгән укучылар өчен РИУ мөгаллиме Габдүррәшит Фәизов атнага ике көн дәрес уздыра.

- Габдүррәшит безнең балаларны Коръән укучылар бәйгесенә дә әзерли, - ди директор. - Бәйгенең таләпләре елдан-ел катгыйлана бит. Безнең укучылар ничә ел рәттән II урынны яулады инде.

Моннан тыш шәһәрнең башка мәктәпләреннән аермалы буларак, "Госмания"дә чит тел итеп беренче урында гарәп теле тора. Укыту планы нигезендә укучылар аны II сыйныфтан өйрәнә башлый. Күрәсең, шуңадыр гарәп теле буенча шәһәр олимпиадаларында "Госмания" укучыларына тиңнәр юк икән. V сыйныфтан инде чит телләр исемлегенә инглиз теле өстәлә. Аңа кадәр балалар бу тел белән факультатив дәресләрдә, түгәрәкләрдә таныша.

- Үзебезнең спорт залы, химия, физика классларыбыз юк, - дип проблемалары белән дә уртаклашты Илсур Фатыйхов. - Килешү буенча без бу дәресләрне 14 гимназиядә уздырырга тиеш. Лаборатор эшләргә балалар шунда йөри. Ләкин көзге салкын яңгырда, кышын карлы-буранлы көннәрдә укучыларны анда җибәрергә кызганабыз. Мәчетнең подвалын спорт залы итеп җиһазладык, һава өрдерергә махсус җайланмалар куйдык. Бу эшләрне "Нурислам" мәчете имам-хатыйбы Фәнис хәзрәт ярдәме белән башкарып чыктык. Балалар шунда да шөгыльләнә. Егетләребез спорт төрләреннән дзюдоны үз итә. Шуның буенча быел алты мәктәп арасында алты беренче урынны алдылар.

"Госмания" мәктәбендә булып кайткач, миңа шунысы кызык тоелды: укучыларның аудиториясе киң анда. Күпләр мәктәптә үзебезнең республика балалары гына белем ала дип уйлыйдыр. Чынлыкта исә әлеге уку йортында бөтен Рәсәйдән җыелган малайлар һәм кызлар гыйлем туплый. Илсур хәзрәт әйтүенчә, әлеге гомуми белем бирү мәктәбен бердәнбер дияргә мөмкин. Шуңа да мөселманнар үз балаларын биредә укыту өчен, йорт-җирләрен сатып, читтән Татарстанга күченеп килә икән.

- Укучылар арасында төрле милләт вәкилләре - ислам динен кабул иткән руслар да, башкортлар да, кыргызлар да, үзбәкләр дә бар, - ди җитәкче. - Ислам дине кушканча кызларны һәм ир балаларны аерым укыту дәрәҗәсенә ирешә алмыйбыз әле. Чөнки бина тар, кысан. Гәрчә, балаларны аерым укыту хәерле. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) заманыннан ук кызлар белән малайлар бергә йөрмәгән. Күргәнебезчә, мәчетләрдә ирләр һәм хатын-кызларның намаз уку урыннары аерым. "Бер сафка басып укылган намаз бозыла, яңадан аерым басып намазны кайтарырга кирәк", - диелә. Сафка тезелгәндә дә, алга саусәламәт ир-атлар, аннары балалар, алар артына авыру ирләр баса. Шуннан соң гына хатын-кызларга урын бирелә. Боларны күздә тотып, дәресне игътибар белән тыңласыннар, фикерләре чуалмасын, шәһвәтләре комачауламасын, егетләр кызлар яки, киресенчә, кызлар егетләр каршында чыгыш ясарга оялмасын өчен малайлар - алдагы, кызлар арттагы өстәлләрдә утыра. Аларга ялгызы гына калырга да рөхсәт бирмибез.

- Илсур хәзрәт, бердәм дәүләт имтиханнары тапшыру мәсьәләсе сездә ничек куелган? - дип сорыйм.

- Безнең укучылар да бердәм дәүләт имтиханнарыннан азат түгел, - ди директор. - Укучылар дәүләт сынауларын имтихан кабул итү пунктына барып тапшыра. Традицион имтиханнарны үзебезнең укытучылардан төзелгән комиссия кабул итә. Быел сыйныфлар саны тугыз гына иде. Алдагы елда укучылар X һәм XI сыйныфка калмады, кемдер "Мөхәммәдия"гә, кемдер башка уку йортына китте. IX сыйныф укучылары гына имтихан тотты.

"Госмания" мәктәбендә белем алучылар укуларын, гадәттә, РИУда, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә, КФУның Шәрыкны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институтында дәвам иттерә, араларында педагогика көллиятләрен сайлаучылар да бар икән. Кайчандыр безнең мәктәп турында төрле сүзләр йөрде, бездә белемне начар бирәләр дип әйтүчеләр дә булды, - ди Илсур хәзрәт. - Кадрлар мәсьәләсе белән авырлыклар туды, хезмәт хакы белән тоткарлыклар чыгып, мөгаллимнәр эштән китте. Мин директор булып килгәндә мәктәпнең 500 мең сум бурычы бар иде. Аллага шөкер, бүгенге көндә укытучыларга әҗәтем юк.

Шәхси мәктәп булып саналса да, "Госмания"дә белем алу бушлай. Балаларның әти-әниләре хәйрия акчасы гына түли. Ел дәвамындагы бөтен чыгымнарны исәпләгәндә, моңа торак-коммуналь хезмәтләр, хезмәт хакы, дәреслекләр сатып алу, косметик ремонт ясау, балаларны ашату-эчертү, мәктәптән тыш чаралар уздыру һ. б. керә, ким дигәндә, 3 миллионнан артып китә.

- Мөселман кешеләре авырлыкларны белә, үзләреннән өлеш кертә, - ди Илсур хәзрәт. - Аллага шөкер, зарланмыйбыз, ярдәм итүчеләр табылып тора. Шунысы бераз күңелне борчый: олимпиада кебек чараларда җиңү яуласак та, бүләген бирмиләр. "Сезгә гранд та каралмаган", - диләр. Гәрчә без дә башка хөкүмәт мәктәпләре кебек үк дәүләт таләпләрен үтәп тиешле белем бирсәк тә.

Дмитрий Медведев 2011 елда шәхси һәм дәүләтнеке саналган барлык гомуми белем бирү мәктәпләренең тигез хокукка ия булулары турындагы указга кул куйды. Ләкин болар кәгазьдә кала, һаман акча бүлеп бирелми. Шәхси мәктәпләргә хөкүмәт ярдәм итәргә атлыгып тормый. Илсур хәзрәт әйткәнчә, хәтта иң яхшы булган очракта да аларга тиешле бүләкне бирмиләр. Моны ничек аңларга? Мәктәп нинди генә булса да анда бит Россия балалары белем ала. Бездә, ягъни Татарстанда, әлеге мәсьәләгә түрәләребез аеруча игътибарлы булырга тиеш, минемчә.

**Энҗе БАСЫЙРОВА**
**"Идел" журналыннан алынды**

# Дин әһелләрен армиядә хезмәт итүдән азат иттеләр

**РФ Хөкүмәте рәисе Дмитрий Медведев руханиларны хәрби хезмәткә алуны кичектерүне караган указга кул куйды. Моннан тыш, Премьер дин тотучылар белән эш итүче командир ярдәмчесе вазифасын башкару өчен кирәкле руханиларның махсус курслар үтү кагыйдәләрен раслады.**

Указ буенча, хәрби хезмәтне кичектерүне ел саен 150 кеше алачак. Ул дини оешмалар соравы буенча биреләчәк. Хәрби хезмәт итүне кичектерүне рухани дәрәҗәсе булган һәм дини оешмаларда эшләгәннәр, дин тотучылар белән эш итүче командир ярдәмчесе вазифасын башкару өчен махсус курслар үтү шарты белән ала алачаклар (хәзерге вакытта Россия армиясендә хезмәт итүчеләр рәсми рәвештә шулай атала).

Шулай ук бу указ хәзерге вакытта армиядә рухани вазифасын башкаручыларга да кагылачак. Семинариядә укучыларга указ кагылмый, алар хәрби хезмәткә башкалар белән беррәттән алыначак.

Хәрби хезмәтне кичектерү православие, яһүд, ислам һәм будда дин әһелләре өчен 2008 елга кадәр булган. Шул вакыттагы указ өч йөз кешегә кагылган. Соңрак Владимир Путин, хәрби хезмәтнең вакыты кыскару сәбәпле, указны гамәлдән чыгара. Бу руханиларда канәгатьсезлек уята. "Церковь, государство и общество" соборы төркеменә кергән 24 архиерей ил җитәкчеләренең "мондый инициативасы рухи мәгарифне һәм тулаем Рус православ чиркәвенең җәмгыятьтә әхлаклылык тәрбияләү урынын аңлап бетермәүләрен күрсәтә" дигән фикергә килде. Иерархлар фикере буенча, руханиларның армиядә капелланнар буларак хезмәт итүе илгә күбрәк файда китерә алыр иде.



Ил белән Дмитрий Медведев җитәкчелек итә башлагач, ситуация үзгәрә башлый: 2009 елда армиядә дин тотучылар белән эш итүче командир ярдәмчесе вазифасын кертәләр. Башкача әйткәндә, армиядә дин тотучыларның дини ихтыяҗларын канәгатьләндерүче дин әһелләре барлыкка килә. 2011 елда хәрби хезмәттәге дин әһелләрен замполит дәрәҗәсенә тиңлиләр. Алар хезмәт итүчеләрне тәрбияли һәм әхлакый инструктаж бирә ала. Д.Медведев инициативасына карамастан, бүгенге көндә армиядә тагын 90 % дин әһеле җитми, дип хәбәр итә "Российская газета".

# Дәүләтнең дини сәясәтендә – либеральләштерү

**Бөек Ватан сугышыннан соң, илебездә дингә ышанучыларның дини тормышы дәүләтнең дини сәясәтенең чагыштырмача либеральләшү фонында бара.**

Узган гасырның утызынчы елларында, мәчетләрне тоталь ябулар һәм профессиональ дин эшлеклеләренә карата алып барылган репрессияләр нәтиҗәсендә, сугыш азагы чорына гыйбадәт йортлары саны нык кимегән, мәсәлән, Башкортстан территориясендә генә дә, 1927 елны булган ике мең ярым мәчеттән 12 рәсми теркәлгән мәчет торып калган. Билгеле, республиканың бар мөселман халкының дини тормышы шул унике мәчеткә генә кайтып калмаган, әлбәттә. Бу тормышның авырлык үзәге әкренләп өйләргә, гаиләләргә күчкән, ә диндарлык исә чит күзләрдән ныклап яшерелгән, нигездә тормыш-көнкүреш даирәсенә күчкән.

Мөселманнарның дини тормышлары һәм көн саен Исламга мөрәҗәгать итүләре сизелмичә үткән. Авылларда эшли торган мәчетләрдә дини йолалар башкарылган, аларга, җомга көннәрендә, 5-10 кеше килгән. Өйләрдә башкарылган бар йолаларны, тормыш-көнкүрештәге динилекнең исәбен, хәтта барысын да күреп торучы СРК вәкиле дә күзәтеп бара алмаган. Шуңа да карамастан, аның отчётлары буенча, ул вакытларда да авылларда балаларны сөннәткә утыртучы "сөннәтче бабайлар" йөргән булган.

Дини тормышның дәвам итүе дини бәйрәмнәрне билгеләп үткән вакытта аеруча яхшы күренгән. Мөселманнар ел саен Ураза, Корбан һәм Мәүлид бәйрәмнәрен билгеләп үткәннәр. Бәйрәм көннәрендә эшчәнлекләрен алып баручы мәчетләр каршында, шул ук вакытта эшчәнлекләрен алып бармаучылары каршында да, зур халык төркемнәре җыела торган булган. Сугыш беткәннән соң үткәрелгән беренче мөселман бәйрәмен - Ураза бәйрәмен билгеләп үтәр өчен (ә ул 1945 елның 7 сентябренә туры килгән) Уфаның Җәмигъ мәчетенә генә дә өч мең кеше җыелган. Ә шул ук елның Корбан бәйрәмен бәйрәм иткән вакытта (1945 елның 15 ноябре) ун мең кеше катнашкан. XX йөзнең 50 нче еллары башына кадәр бәйрәм көннәрендә мәчетләргә килүчеләрнең саны чагыштырмача бер тирәдәрәк булган. Мәчеткә килүчеләрнең 10-30 проценты хатын-кызлар булган, алардан тыш, Үзәк мәчетләрдә, ата-аналары белән килгән 30-50 бала да дини йолаларны башкаруда катнашкан.

Ураза бәйрәме белән төгәлләнә торган рамазан аенда, һәр төн саен тәравих намазы укыганнар, җомга көннәрендә Үзәк мәчетләргә җомга намазына 200-250 кеше килгән, ә өлкән яшьтәгеләр ураза тотканнар (якынча йөз иллешәр кеше). Бу вакытта хакимият органнары ураза тоту һәм дини бәйрәмнәрне бәйрәм итү, җәмәгать тәртибендә, эшкә йөрүдә, хезмәт дисциплинасында

(Ахыры 4 нче биттә.)

# Дәүләтнең дини сәясәтендә – либеральләштерү

(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)

чагылыш алмавын зур таләпчәнлек белән күзәтеп торганнар.

Ураза тотучы мөселманнарга көндез эшләргә туры килгән. Күпләре ураза тотуларын яшергәннәр. "Ураза тотучылар әңгәмәләр үткәреп ачыкланды, тик барысы да ураза тотуларын танып бармыйлар. Ураза тотуларын күрсәтмәскә тырышалар, чөнки бу аларда шәригать буенча тыелган гамәл, мактану булып исәпләнә", - дип яза СРК вәкиле.

Корбан бәйрәме вакытында корбан итеп, дин кагыйдәләренә туры китереп сарыклар чалганнар, аның итен пешереп бәйрәм сыйлары оештырганнар, итнең бер өлешен туганнарына, күршеләренә таратканнар. 1947 елны Уфада корбанга илле сарык чалынган, ун сарык тиресе муллаларга хәер итеп бирелгән. Ә бар Башкортстан буенча, барысы өч мең сарык чалынып, алар тиресенең 30 процентына кадәр дәүләт әзерләү оешмаларына сатып тапшырылган.

Корбан бәйрәме вакытында мөселманнарның өйләрендә башка мөселманнарны һәм муллалар чакырып корбан ашлары үткәргәннәр. Бәйрәм сыйлары үткәрүче мөселманнар шулкадәр күп булган, алар муллаларны чакырыр өчен чиратка языла торган булганнар. Ә муллаларга исә, үз көннәрен сәгатьләп планлаштырырга туры килгән. Мөселманнар өчен Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көненә багышланган Мәүлид бәйрәме изге көн булып исәпләнә. Өч көн бара торган бу бәйрәм вакытындагы вәгазьләрдә Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) турында сөйләнә. Көндез күп урыннарда Мәүлид ашы үткәрәләр. "Мөселман бәйрәмнәре көннәрендә халык мәчетләргә шатланып, күтәренке күңел белән килә", - дип шактый еш билгеләп бара вәкил. Мәчетләргә мөселманнар гына түгел, ә кызыксынып, шәһәр халкы да килә. Алар арасында татарлар да, башкортлар да, башка милләт вәкилләре дә була. Мәчетнең ишегалдында күп санда теләнчеләр була, алар өчен бу көннәр аеруча зур уңыш белән тәгәлләнә. Өлкән яшьтәгеләр бу йолаларда катнашучыларның 70 процентын тәшкил иткән, ә яшьләр исә биш процентын.

Дини йолаларны башкарырга килүчеләр, гадәттә, ун-унбишәр кешелек төркемнәргә җыелып, юлда барган вакытта ук ритуаль тәкбир әйтеп мәчеткә бара торган булганнар, чатларда, тыкрыкларда туктап, кычкырып Аллаһны олылаганнар.

Мөселманнарның хәер-сәдакалары мәчетләрнең генә түгел, ә Диния нәзарәтенең дә табышларының төп матдәсе булган. Гадәти көннәрдә регуляр керемнәр зур булмаган. Аның урынына, мөселман бәйрәмнәре көннәрендә мөселманнардан акча җыю үткәрелгән һәм Диния нәзарәтенең казнасы нык кына тулыланган. Җыелган бар хәйрия акчалары да, Диния нәзарәтен, мәхәлләләрдәге мәчетләрне тотарга, мәчет, зиратларны төзекләндерергә, хаҗга баруны оештырырга, ятимнәргә ярдәм итәргә һәм башка хәйрия максатларына бүлеп тотылган.

Шунысын да әйтеп үтик, сүз рәсми рәвештә теркәлгән мәхәлләләр, дини җәмгыятьләр турында бара. Ачык күренеп тора, андый сандагы рәсми теркәлгән дини җәмгыятьләр генә бар мөселманнарның да дини ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмаган. Нәтиҗәдә, мөселманнарның күп өлеше "рәсми теркәлмәгән" дип аталучы дини җәмгыятьләргә (егерме һәм аннан да күбрәк сандагы) һәм дини төркемнәргә (5-10 кеше) берләшергә мәҗбүр булганнар. Күп кенә дини җәмгыятьләрнең эшчәнлеге 1941 елларга кадәр үк, ә кайберләре исә сугыш башланыр алдыннан гына тыелган булган. Һәм шуңа да, мөселманнар үзләренең ул җәмгыятьләрен канунсыз дип исәпләмәгәннәр, аеруча 1946 елның 28 гыйнвар постановлениесеннән соң. Мәчетләрне һәм дини җәмгыятьләрне торгызу буенча гариза бирү, алар фикеренчә, дини эшчәнлекне дәвам итәргә җитәрлек нигез булып торган.

Теркәлмәгән дини җәмгыятьләрнең, кагыйдә буларак, үз дин әһелләре булган. Гадәттә, элеккеге муллалар. Һәрхәлдә, аларны шундый сыйфатта таный торган булганнар. Төркемнәрне очраклы кешеләр җитәкләгән, алар шул ук вакытта дини хезмәтләр, йолаларны башкару функцияләрен дә үз өсләренә алганнар. Алар, гадәттә, Коръән, догаларны, дини кагыйдәләрне яхшы белгән өлкән яшьтәге кешеләр булганнар.

Андый төркем һәм җәмгыятьләрнең булуы җирле хакимият органнарын, СРК вәкилен зур хафага төшергән. Соңгысы, теркәлү алмаган җәмгыятьләрнең эшчәнлеге турында үзенә ни дә булса мәгълүм булган саен, шунда ук куркынычсызлык органнарына җиткергән: "Куркынычсызлык министрлыгына. Сезнең игътибарыгызга шуны җиткерәм, кайбер район һәм шәһәрләрдә, элеккеге мулла һәм башка дин эшлеклеләре җитәкчелегендә, төрле мөселман төркемнәре, дини йолалар башкару өчен рәсми рөхсәт алмыйча, гыйбадәт кылалар... Алда санап үтелгән бар бу төркемнәр дә, якында эшләп килүче гыйбадәт йортларына кушылырга төрлечә каршы баралар. Элеккеге дин әһелләре, салымнар түләүдән читләшер өчен төркемнәрен легальләштермиләр... - Кәримов".

Рәсми теркәлү үткән җәмгыять мөселманнары дини йолаларны, күп халык җыелган мәчетләрдә башкарганнар, дини йолалар муллалар җитәкчелегендә үткәрелгән. Эшләүче мәчетләрнең саны аз булу аркасында, мөселманнарның күп өлешенә догалар укуны, дини йолалар башкаруны өйләрендә эшләргә туры килгән. Җомга көннәрендә, дини бәйрәмнәр вакытында, алар, шулай да, берәр мөселманның өендә яки ябылган, беркем тарафыннан да файдаланылмый торган иске мәчетләрдә яисә ачык һавада, зиратларда җыелып җәмәгать намазларын укыганнар. Андый җәмәгать намазларында катнашучылар саны, рәсми теркәлү алган мәчетләрдә гыйбадәт кылучылар саныннан күпкә кимрәк булган, ул 20-100 кеше аралыгында тирбәлгән.

**(Ахыры газетабызның киләсе санында.)**

**Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 13.10.12 | 5:41 | 7:11 | 13:02 | 16:13 | 17:48 | 19:18 |
| Якшәмбе | 14.10.12 | 5:43 | 7:13 | 13:02 | 16:11 | 17:45 | 19:15 |
| Дүшәмбе | 15.10.12 | 5:45 | 7:15 | 13:02 | 16:09 | 17:43 | 19:13 |
| Сишәмбе | 16.10.12 | 5:47 | 7:17 | 13:02 | 16:07 | 17:40 | 19:10 |
| Чәршәмбе | 17.10.12 | 5:49 | 7:19 | 13:02 | 16:06 | 17:38 | 19:08 |
| Пәнҗешәмбе | 18.10.12 | 5:51 | 7:21 | 13:02 | 16:04 | 17:35 | 19:05 |
| Җомга | 19.10.12 | 5:53 | 7:23 | 13:02 | 16:03 | 17:33 | 19:03 |
| Шимбә | 20.10.12 | 5:55 | 7:25 | 13:02 | 16:01 | 17:31 | 19:01 |

**Бараны на Курбан-байрам. Забой, доставка.Тел.: 89046683857 (Артур)**




# ТРАДИЦИОН ИСЛАМ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)

дип әйтергә дә мөмкин (традицион ислам дин галимнәре фикеренчә, Исламда иман төшенчәсе - дингә ышануны тел белән әйтү һәм аны күңелгә, йөрәккә сеңдерү). Иманның өч өлешле булуы турында сөйләгәндә, гамәлләрнең дә иманның бер өлеше булуы турында әйтелә. Мондый фикер буенча, әгәр дә саваплы гамәлләр булмый икән, мәсәлән, кеше намаз укымый яки гөнаһлар кыла икән, мондый кеше кяфер булып исәпләнә".

Исламны аңлауда хәзерге вакытта агрессив көрәш бара, хәзрәтләр фикеренчә, иманны ике өлешле итеп аңлатуны юк дәрәҗәсенә төшерү, андый агрессив көрәшнең бер пункты. Сәләфиләр идеологиясе Исламны өч өлештә аңлатуны, максатчан рәвештә, көчләп тагарга тырыша дип раслыйлар алар. Алар (сәләфиләр), хәтта, татар китапларын бозып, үзгәртеп күрсәтүгә кадәр барып җитәләр. Ике өлешле аңлатудан баш тарту, аларның сүзләре буенча, кемнең дөрес итеп киенүе, кемнең чын мөфти, ә кемнең "чын түгел" икәнлеге, кайсы имам хак имам, ә кайсысының хак түгел икәнлеге турында хөкем чыгарырга мөмкинлек бирә, диләр. Кеше үз өстенә хөкем чыгаручы хокукын алган вакытта, бу терактлар һәм башка куркыныч гамәлләр белән яный.

Теракт эшләгән кешеләр дә үзләрен мөэмин-мөселман дип исәплиләр. "Алар үз диндәшләрен һәлак иткән вакытта, бу гамәлләрендә үз-үзләрен ничек тә булса аклау өчен, корбаннарының иман төшенчәсен өч өлешле итеп аңламауларын, шул сәбәпле башкаларны мөселман итеп исәпләмәүләрен дәлил итеп китерәләр, - дип дәвам итте Рөстәм хәзрәт. - Ә бу исә, аларның фикер йөртүләренең нигезендә ята. Аларның күңелендә һаман да шул бер үк аклану: "кяферләрнең гамәлләре хак гамәл түгел, ул гөнаһ кылган, димәк, ул кяфер, шуңа да, мин аны ничек телим, шулай хөкемгә тарта алам" диләр".

Хәнәфи мәзһәбенең төп үзенчәлеге - аның акылга сыешлы (рациональ) булуында. Шул нигездән - милли гореф-гадәтләр, йолалар идеясе дә. Әгәр дә халык берничә гасыр буена ниндидер гореф-гадәтләр үти икән, бу болай гына, бернинди дә сәбәпсез эшләнми, ә мәсьәләгә акыл белән якын килү нәтиҗәсе буларак тормышка ашырыла. Хакыйкать, бар дөнья буенча таралган вакытта, котылгысыз, төрле дәверләрнең, төрле җирлекләрнең тарихи рәвешен ала. "Бу гореф-гадәтләр тормыш чынбарлыгыннан хасил булалар. Аларны кире кагу - ахмаклык", - ди Рөстәм хәзрәт.

Р.Батыр шул ук вакытта, ни өчен сәләфиләр мәзһәбе яшьләргә нык ошый дигән сораугада җавап бирде. Аның фикеренчә, "традицион исламда, артык сүз әйтүдән кыенсынып, 40 яшең тулганчы өлкәнрәкләргә бары тик "чәй китереп торырга гына рөхсәт ителгән" булса, ә традицион булмаганында - Коръән белән Сөннәтне кулыңа ал да, күкрәгеңне киереп, үзең теләгәнчә аңлат".

**Нияз САБИРҖАНОВ**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 15 (158) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9420.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 11 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**